## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 ел, 24 ноябрь** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 24 ноябрендә 14.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2023 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; ялгыз,өлкән булган затлардан; Украина территориясендә хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

1) Ләшәү Тамак авылы территориясендә җәйге чорда үлән чабу өчен триммер сатып алу;
2) Ләшәү Тамак авылында "МТЗ-82" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;
3) Ләшәү Тамак авылында Сабантуй мәйданын төзекләндерү өчен материаллар сатып алу;
4) Ләшәү Тамак авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампочкалар һәм яктырткычлар сатып алу);
5) Ләшәү Тамак авылында массакүләм чаралар (Сабантуй) үткәрү өчен бүләкләр алу;
6) Җәйге чорда авыл территориясен чабу өчен триммерга ГСМ алу һәм договор нигезендә эш башкаручыга түләү;
7) Ләшәү Тамак авылында кышкы чорда кар чистарту өчен ротор сатып алу ;

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 141 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 84 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 84 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныйрга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныйрга.

2. «2023 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; Украина территориясендә хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, ялгыз өлкән булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Ләшәү Тамак авылы территориясендә җәйге чорда үлән чабу өчен триммер сатып алу;
2) Ләшәү Тамак авылында "МТЗ-82" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;
3) Ләшәү Тамак авылында Сабантуй мәйданын төзекләндерү өчен материаллар сатып алу;
4) Ләшәү Тамак авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампочкалар һәм яктырткычлар сатып алу);
5) Ләшәү Тамак авылында массакүләм чаралар (Сабантуй) үткәрү өчен бүләкләр алу;
6) Җәйге чорда авыл территориясен чабу өчен триммерга ГСМ алу һәм договор нигезендә эш башкаручыга түләү;
7) Ләшәү Тамак авылында кышкы чорда кар чистарту өчен ротор сатып алу ;

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче И.З.Хабибуллин